Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

26 декабрь 2006 ел №138

Әлмәт муниципаль районы
әләме турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 9 нчы маддәсенә, Әлмәт муниципаль районы Уставының 3 маддәсенә нигезләнеп,

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Әлмәт муниципаль районы әләме турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы әләменең рәсемен расларга (күптөсле вариантта) (2 нче кушымта).

3. Әлмәт муниципаль районының әләм турындагы документларын Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советына һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Геральдика советына вексиллологик экспертизага һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы геральдик регистрларында теркәү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныӘлмәт муниципаль районы Советының закон, хокук саклау, депутат этикасыһәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе И.А.Володкинга йөкләргә.

Әлмәтмуниципаль районы башлыгы Р.Ф. Әбүбәкеров

Татарстан Республикасы  Әлмәт
муниципаль районы Советының
2006 елның 26 декабрендәге
№ 138 карарына1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Әлмәт муниципаль районы җирлегенең әләме турында**
**нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль берәмлегенең әләмен билгели, аның тасвирламасын һәм рәсми рәвештә ничек кулланылырга тиешлегенә ачыклык кертә.

## 1. Гомуми нигезләр

1.1.Татарстан РеспубликасыӘлмәт муниципаль районы җирлеге әләме (алга таба – Әлмәт муниципаль районы әләме) Әлмәт муниципаль районы гербына нигезләнеп, вексиллология традицияләренә җавап бирә, шулай ук җирле һәм тарихи, мәдәни, иҗтимагый-икътисади, милли традицияләрне чагылдыра торган итеп җитештерелә.

1.2.Әлмәт муниципаль районы әләме турындагы нигезләмә һәм аның оригинал сүрәте Әлмәт муниципаль районы Советында саклана. Кызыксынучылар булса, аның белән танышу мөмкинлеге бирелә.

## 2. Әлмәт муниципаль районы әләменең дәрәҗәсе

2.1. Әлмәт муниципаль районы әләме Әлмәт муниципаль районының рәсми символы булып санала.

2.2.Әлмәт муниципаль районы әләме Россия Федерациясе Дәүләт геральдика регистрына һәм Татарстан Республикасы Геральдика регистрына кертелергә тиешле.

## 3. Әлмәт муниципаль районы әләме символикасының тасвирламасы һәм дәлилләмәсе

3.1.Әлмәт муниципаль районы әләменең тасвирламасы:

“Әләм киңлеге аның озынлыгына карата 2:3не тәшкил итүче турыпочмаклы яшел тукымадан гыйбарәт, аскы чите буйлап ¼ киңлектә кызыл буй сузыла, ә уртада герб фигурасы балкып тора: үтәкүренмәле сары лалә чәчәгенең буе тукыма буена 4/5 өлешне тәшкил итә, чәчәкнең эчендә, кызыл буйга җитеп үк диярлек, кара фонтанга сөяп куелган баскыч төшерелгән”.

3.2.Әлмәт муниципаль әләме символикасының дәлилләмәсе.

Әләм Әлмәт муниципаль районы гербына нигезләнеп эшләнгән.

Әлмәтнең тарихы XVIII гасырның беренче чирегенә барып тоташа. Ул чакта бу урында Әлмәт дигән авылга нигез салына. Акрынлап авыл эшчеләр бистәсенә әверелә, ә 1953 елда инде ул шәһәр булып оеша. Әлмәтнең шәһәр дәрәҗәсенә үсеп җитешүе биредәге нефть ятмаларын киң колачлы үзләштерү һәм өйрәнү белән бәйле.

Бүген Әлмәт районы –Татарстандагы эре нефть чыгару үзәге. Россиянең иң алдынгы оешмаларыннан берсе булган “Татнефть” ААҖ Әлмәттә урнашкан. Ул районыбызның гына түгел, ә тулаем республиканың да икътисадыйһәм иҗтимагый тормышы үсешенә зур өлеш кертә.

Районыбызның әлеге үзенчәлеге кара фонтанга илтүче сары (алтын) баскычны сурәтләгәндә чагылыш тапты. Сары (алтын) баскыч – нефть вышкасының аллегорик тасвирламасы ул. Сары (алтын) белән кара төсләрнең ярашуы нефтьнең үз билгеләмәсенә дә барып тоташа – без бит бу байлыкны юкка гына “кара алтын” дип йөртмибез.

Сары (алтын) төс – уңыш, муллык, интеллект һәм ихтирам символы.

Кара төс – акыл, зирәклек, тыйнаклык һәм ихласлык символы.

Сары (алтын) лилия Әлмәт районының үсеше, чәчәк атуы, даны һәм шөһрәте турында сөйли. Моннан тыш, чәчәк төрки халыкларның сәнгатендәге иң популяр үсемлек бизәкләренең берсе булып исәпләнә, ул аллегорик рәвештә җир тарихын чагылдыра.

Әләмнең төсләр гаммасы, шул рәвешле, табигать белән сәнәгать җитештерүенең үзара ярашуын исбатлый. Яшел буй районның географик үзенчәлекләренә ишарә итә – безнең табигать искиткеч матур. Яшел төс – табигать, яшьлек, сәламәтлек, тормыш төсе.

Кызыл буй Әлмәт районында сәнәгать җитештерүенең алга киткән икәнлегенә ишарә – без бит көньяк-көнчыгыш төбәкнең егәрле индустрия үзәге. Кызыл төс – гайрәт, көч, хезмәт сөючәнлек, матурлык һәм бәйрәм төсе.

3.3.Авторлар төркеме:

Әләм авторлары: Рафаэль Курамшин (Әлмәт), Марат Исламов (Әлмәт).

Әләмне эшләп бетерү белән Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы һәм Россия геральдистлары Берлеге әгъзалары: Рамил Хәйретдинов (Казан), Радик Салихов (Казан), Константин Моченов (Химки), Галина Русанова (Мәскәү), Кирилл Переходенко (Конаково)шөгыльләнделәр.

## 4. Әлмәт муниципаль районы әләмен җитештерү тәртибе

4.1.Әлмәт муниципаль районы әләмен җитештерү, аны башкару размерлары һәм техникасына бәйле булмаган рәвештә, әлеге нигезләмәнең 3 нче маддәсе, 3.1 пунктында искә алынган геральдик тасвирламага тулысынча туры килергә тиеш.

Әләм рәсемен үзгәртү (бозу), геральдик яктан мөмкин булганнан чиккә чыга торган итеп композицияне һәм төсләрне алмаштыру өчен җаваплылыкны бу эшне башкарган кеше ала.

## 5. Әлмәт муниципаль районы әләмен рәсми рәвештә куллану тәртибе

5.1.Әлмәт муниципаль районы әләме һәрчак күтәреп куелган хәлдә булырга тиеш:

- муниципаль милек булып исәпләнгән җирле үзидарә органнары биналарында, оешмаларында, учреждениеләрендә;
- Әлмәт муниципаль районыннан читтә булган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан рәсми вәкиллекләрдә.

5.2. Әлмәт муниципаль районы әләме җирле үзидарә органнарының утырышлары вакытында һәрчак урнаштырып куелган була, шулай ук ул җирле үзидарә белән шөгыльләнүче сайлап куелган хезмәткәрләрнең эш кабинетларында, муниципаль милек булып исәпләнгән предприятиеләрдә, оешмаларда һәрчак эленеп тора.

5.3. Әлмәт муниципаль районы әләме урнаштырыла:

- Әлмәт муниципаль районы башлыгы йөри торган транспортка, шулай ук җирле үзидарәнең башка хезмәткәрләренең транспортына;
- муниципаль милек булып исәпләнгән транспортка.

5.4. Әлмәт муниципаль районы әләме җирле үзидарә уздыра торган рәсми церемонияләр һәм башка тантаналы чаралар вакытында күтәреп куела.

5.5. Әлмәт муниципаль районы әләме милек формасы буенча ирекле булган оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр, берләшмәләр уздырган тантаналы чаралар уздырылганда да, хәтта гаилә бәйрәмнәре вакытында да күтәреп куелырга (урнаштырылырга) мөмкин.

5.6. Матәм билгесе булганда Әлмәт муниципаль районы әләменең таягындагы өске өлешкә кара тасма беркетелә, аның озынлыгы әләм тукымасының озынлыгына тәңгәл. Матәм билгесе булганда, Әлмәт муниципаль районы әләме мачтага яки флагштокка урнаштырыла, әмма ул мачта белән флагштокның биеклеге буенча яртысына кадәр төшереп куелган булырга тиеш.

5.7. Татарстан Республикасы һәм Әлмәт муниципаль районы әләмнәре берьюлы күтәрелгән (урнаштырылган) очракта Әлмәт муниципаль районы әләме Татарстан Республикасы әләменнән уңдарак урнашкан булырга тиеш (әгәр аларга йөз белән карап торсаң).

Җөп санлы әләмнәр берьюлы күтәрелгән (урнаштырылган) очракта (икедән артык түгел), Россия Федерациясе Дәүләт әләме үзәктән сулгарак куела (әгәр аларга йөз белән карап торсаң). Россия Федерациясе Дәүләт әләменең уң ягында Татарстан Республикасы әләме урнаштырыла, Россия Федерациясе Дәүләт әләменнән сул якка Әлмәт муниципаль әләме куела; Татарстан Республикасы әләменнән уң якта башка муниципаль җирлекнең әләме урнаштырыла, шулай ук иҗтимагый оешманыкы, берләшмәнеке, предприятиенеке, учреждениенеке дә була ала.

5.8. Россия Федерациясе Дәүләт әләме, Татарстан Республикасы һәм Әлмәт муниципаль районы әләмнәре берьюлы күтәрелгәндә (урнаштырылганда), Россия Федерациясе Дәүләт әләме уртада булырга тиеш. Сул ягында Татарстан Республикасы әләме урнаштырыла, уңда исә – Әлмәт муниципаль районы әләме (әгәр аларга йөз белән карап торсаң).

Берьюлы өчтән дә күбрәк әләмнәр күтәрелгән (урнаштырылган) очракта Россия Федерациясе Дәүләт әләме уртада урнаштырыла (әгәр аларга йөз белән карап торсаң).

5.9. Әлмәт муниципаль районы әләме Россия Федерациясе Дәүләт әләменнән, Татарстан

Республикасы әләменнән, шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектларыныкыннан да зуррак булырга тиеш түгел, биеклеге буенча да – шулай ук.

5.10. Әлмәт муниципаль районы әләме элемент яисә геральдик нигез буларак Әлмәт муниципаль районы һәм аның җирле үзидарә органы вәкаләте тапшыра торган һәртөрле билгеләрдә, бүләкләрдә чагылыш табарга мөмкин.

5.11. Әлмәт муниципаль районы әләме рәсеме урнаштырыла ала:

- Әлмәт муниципаль районы башлыгы бланкларында, шулай ук җирле үзидарәнең башка сайлап куелган хезмәткәрләренекендә дә;

- җирле үзидарәнең вәкаләтле органы һәм башка органнары бланкларында;

- җирле үзидарә милеге булып исәпләнгән предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның бланкларында;

- җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәгә сайлап куелган хезмәткәрләрнең норматив хокукый актлар бланкларында;

- җирле үзидарә милеге булып исәпләнгән органнар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның рәсми басмаларында;

- шәһәр башлыгының, җирле үзидарә органнарында вазыйфаи эш башкаручыларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы депутатлары таныклыкларында; җирле үзидарәнең башка органнары әгъзалары, муниципаль милек булып исәпләнгән предприятие, учреждение һәм оешмаларның хезмәткәрләре (эшчеләре) таныклыкларында;

- Әлмәт муниципаль районы башлыгы исеменнән тапшырыла торган билгеләр һәм бүләкләрдә;

- җирле үзидарәнең һәртөрле тамгаларында, бүләкләрендә;

- муниципаль милектә булган транспорт чараларында.

5.12. Әлмәт муниципаль районы әләмен урнаштырырга мөмкин:

- Әлмәт муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чараларында, туган якны өйрәнү басмаларында;

- җирле үзидарә хезмәткәрләренең, җирле үзидарә вәкаләтле органы депутатларының грамоталары, чакырулары, визит карточкаларында; шулай ук аны нинди дә булса тантаналар, чараларның тамгаларын, эмблемаларын, символикасын әзерләгәндә яки бизәү өчен кулланырга була.

5.13. Әлмәт муниципаль районы әләме төшерелгән бланкларны һәм башка продукцияне бастыру, әзерләү, куллану, саклау тәртибе Әлмәт муниципаль

районы җирле үзидарәсе органнары тарафыннан билгеләнә.

## 6. Әлмәт муниципаль районы әләмен муниципаль милеккә карамаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан куллану тәртибе

6.1. Әлмәт муниципаль районы әләмен муниципаль милеккә карамаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан куллану тәртибе килешү нигезендә хәл ителә.

6.2. Әлмәт муниципаль районы әләмен куллануның башка төрле очраклары җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи хезмәткәрләре төзегән хокукый актлар нигезендә хәл ителә.

## 7. Әлеге Нигезләмәнең шартлары бозылган очракта каралган җаваплылык

7.1. Әлмәт муниципаль районы әләмен куллану барышында Нигезләмәгә зыян килсә, яисә Әлмәт муниципаль районы әләменә карата мыскыллы мөнәсәбәт барлыгы ачыкланса, башбаштаклык өчен җавап тотучылар һәм аерым очраклар Россия Федерациясе закончалыгында каралган законнарга нигезләнеп хәл ителә.

## 8. Йомгаклау нигезләре

8.1. Әлмәт муниципаль районы әләме составын (рәсемен), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми символларының элементларынүзгәртү күздә тотылса, аңа өстәмәләр кирәк дип табылса, моны бары тик Россия Федерациясе закончалыгы белән килешеп, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына нигезләнеп кенә башкарырга мөмкин. Нигезләмәнең 3 маддәсен күздә тотылган үзгәрешләрне биредә тасвирлар һәм теркәр өчен яңадан карап чыгу сорала.

8.2. Әлмәт муниципаль районы әләмен куллану хокукы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәсе органнары вәкаләтендә.

8.3. Әлмәт муниципаль районы әләме Россия Федерациясенең 1993 елның 9 июлендә расланган № 5351-1“Авторлык хокуклары һәм чиктәш хокуклар” Законы буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан теркәлгәч, авторлык хокукларыннан азат ителә.

8.4. Әлеге Нигезләмәдәге таләпләрнең үтәлешен контрольдә тоту Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла.

8.5. Әлеге Нигезләмә рәсми рәвештә бастырып чыгарылганнан соң үз көченә керә.

*Россия Федерациясе Дәүләт әләмен милек формасы буенча иркле булган иҗтимагый берләшмәләр, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан рәсми рәвештә куллану, шулай ук шәхси йортларда куллану № 1-

КФЗ номерлы 2000 елның 25 декабрендә расланган “Россия Федерациясенең Дәүләт әләме турында” (2002 елның 9 июле үзгәрешләрен кертеп) Россия Федерациясенең Конституцион федераль законының 3 нче, 6 нчы маддәләре буенча башкарыла // “Российская газета”, 2000 елның 27 декабре, № 344 (2608), “Российская газета”, 2002 елның 13 июле, № 127 (2995).

Әлмәт муниципаль районы башлыгы Р.Ф. Әбүбәкеров